**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**“АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН**
**2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

“КАРАЛДЫ”
МБ җитәкчесе

________Замалиева И.Х

МБ утырышы беркетмәсе
№__1__ __25__август 2016 ел

**“КИЛЕШЕНДЕ”**
«2 нче Алексеевск УГББМ”
МБГБУ директор
урынбасары

________Ягудина Л.Р.

__27__ август 2016 ел

**“РАСЛАНДЫ”**
«2 нче Алексеевск УГББМ”
МБГБУ директоры

________Липлянина Л.Н.

__233__ номерлы боерыгы

__31__ август 2016 ел

**Татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Хөснетдинова Гөлия Сөләймановнаның**

**4 “А” сыйныфы өчен татар теле һәм әдәби укудан**

**эш программасы**

Педагогик совет утырышында каралды

__1__номерлы беркетмә

__31__ август 2016 ел

2016-2017 уку елы

**1.Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре.**

Сыйныф: 4 “А”
Укытучы: Хуснутдинова Г.С.
Уку планы буенча татар теле һәм укудан:136 сәг.
Атнага: *4 сәг.*
Сүзлек диктанты: 2
Күчереп язу: 1
Тест: 4
Инша :1
Контроль эш: 4
**Дәреслек:** Р.З. Хәйдәрова, Л.Ә.Гыйниятуллина,Г.М.Әхмәтҗанова ”Күңелле татар теле” Казан “Татармультфильм” нәшрияты, 2014 ел.

Программа: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, 2014 ел.

Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

1. Программа: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фәнминистрлыгы. Урта (тулы) гомумибелембирүмәктәбендәрустеллебалаларга татар теленкоммуникатив технология нигезендәукытупрограммасы (1 — 11 нчесыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, 2014 ел.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомумибелемучреждениясе “Аерымпредметларнытирәнтенөйрәнүче Алексеевск 2 нчеуртагомумибелембирүмәктәбе”неңтөпгомумибелембирүбаскычындабашлангычгомумибелем бирүпрограммасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомумибелемучреждениясе “Аерымпредметларнытирәнтенөйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомумибелеммәктәбе”нең 2016-2017уку елына укыту планы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2016 ел)

Билгеле булганча, укытуның максаты җәмгыять тарафыннан куелган социаль заказ белән билгеләнә. Татарстан Республикасының белем бирү системасына куйган төп бурычы - иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле һәм ике дәүләт һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы билингваль (полилингваль) шәхес тәрбияләү.
Рус телле балаларга татар теле укыту максаты киңкырлы һәм ул берничә аспекттан тора: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.
**1**.Танып белү максатының эчтәлеге

Татарстан Республикасында яшәүче һәрмилләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш,шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннәнфайдаланырга тиеш. Программа эчтәлеге телгә өйрәтү процессын бала өчен “башка дөньяга тәрәзә ачу” (И.Л.Бим) булырлык һәм шуның аркылы аның үз яшәешен дә тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп сайлана.

Татар исемнәрен, Татарстанның табигатен, җирлеген, топонимикасын дөрес әйтә белергә өйрәтү, аларның семантикасы белән кызыксындыру, балалар фольклоры, татар халкы авыз иҗаты, әдәбият-сәнгать вәкилләре белән беренчел таныштыру - башлангыч этапта танып белү максатының төп эчтәлеген тәшкил итә.

2. Үстерү максатының эчтәлеге

Шәхеснең белемле булуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләүсәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора.

Укыту процессында үстерү, тәрбия максатларын даими күзаллап эшләү - укытуның практик ягы уңышлылыгының алшарты (Л.С.Выготский).

Балаларның психик үсешен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар таләп ителә:

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дидуктив фикерләү;
- хәтерне үстерү (ихтыярый, ихтыярсыз), игътибарлылыкны үстерү;
- аралаш белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисселек, эмпатияхисләре);
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне үстерү.

Программага сайланга эчтәлек нигезендә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча да эш оештырганда бу максатлар беренче планга куела.

**3.** Тәрбияви максатның эчтәлеге

Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Тәрбия процессы укытуның эчтәлеге һәм методлары белән бәйле. Шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләрен исәпкә алына. Балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән, аларны кызыксындырган мораль проблемаларны ү зэченә алган эчтәлек, беренчедән, укыту процессында тәрбияви функция башкарса, икенчедән, турыдан-туры коммуникатив мотивация туу белән бәйле.

Башка милләт вәкилләренең күңелен яулардай, аларда гомумкешелек әхлакый сыйфатларны тәрбияләрдәй татар әдәбияты өлгеләре белән таныштыру шушы максатка буйсындырыла һәм сөйләшү-аралашуга алып чыгуга кулайрак булган әдәби әсәрләрнең авторлары тәкъдим ителә.

**4**. Белем бирү максатының эчтәлеге:

Укучыларның татар теле буенчалексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлыктөрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, укучылар, нинди дә булса сүзне, я грамматиккатегорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатында мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.Укучының гомуми урта белем бирү мәктәбен тәмамлаганда сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча түбәндәге белемнәргә ия булуы күздә тотыла.

**<u>Укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр</u>**

**Тыңлап аңлау**

Укытучының дәрес, уен ситуацияләре белән бәйле сорауларын, күрсәтмәләрен аңлау;

тыңлаганда җөмлә, сүз чикләрен билгеләү, интонацияне аеру;

сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетеп аера белү.

сүзләрне, җөмләләрне тыңлап тәрҗемә итә белү;

ишеткән сөйләмнең, җөмләнең эчтәлегенә төшенү.

**Диалогик сөйләм**

Өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;

программада күрсәтелгән темалар буенча укытучының сорауларына жавап бирү һәм сораулар куя белү;

дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

**Монологик сөйләм**

Җанлы һәм җансыз предметларны,рәсем, картина эчтәлеген сурәтләп сөйли белү;

тәкъдим ителгән план, терәк сүзләр ярдәмендә укылган өзек яисә караган рәсем буенча, өйрәнелгән җөмлә төрләрен файдаланып, хикәя төзү;

укыган хикәяләрнең эчтәлеген сөйли белү;

үзе, гаиләсе һәм дуслары турында кечкенә информация бирә белү.

**Уку**

Татар алфавитындагы хәрефләрне таный белү;

хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;

дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;

тексттагы тыныш билгеләренә карата тиешле пауза һәм интонацияләрне үтәү,өтерләр янындагы сүзләрне тиңдәшлек, эндәшү интонацияләре белән уку;

укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;

кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;

укыганда сүзлекләр куллана белү.

**Язу**

Татаралфавитындагыхәрефләрне дөрес, матур яза белү;
дөрес күчереп язу күнекмәләрен булдыру;
бәйрәмнәр белән котлау, чакыру кәгазьләре язу;
конверт һәм дәфтәр тышына яза белү;
программада күрсәтелгән темалар буенча, терәк сүзләр кулланып, хикәя язу күнекмәләре формалаштыру.

**4 нче сыйныфны тәмамлаучы рус телендә сөйләшүче балалар үзләштерергә тиешле белем-күнекмәләр**

1. Татар телендәге хәреф-аваз системасына анализ бирә белү.
2. Исемнәрнең килеш кушымчаларын сөйләмдә дөрес куллану.
3. Исемнәрне күплек санда тартым белән төрләндерү.
4. **Маратның китабы** төзелмәсен сөйләмдә куллану.
5. Кушма, парлы исемнәрнең мәгънәләрен аңлап, сөйләмдә куллану.
6. **Кадәр, соң** бәйлекләре белән таныштыру.
7. Чагыштыру, артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатларның мәгънәләрен аңлап, сөйләмдә куллану.
8. **Монда, анда** күрсәтү алмашлыкларын сөйләмдә куллану.
9. **Мин, син, ул** зат алмашлыкларының иялек, юнәлеш, урын-вакыт килешләрендә төрләнешен сөйләмдә куллану.
10. Билгесез үткән заман хикәя фигыльне III зат берлек санда сөйләмдә куллану.
11. Татар һәм рус телләрендә сүз тәртибе үзенчәлекләр белән таныштыру.
12. И**ртәгә эшлим** конструкциясе белән таныштыру.

**Орфоэпикһәм орфографик минимум.**

1. Сүзбасымы. Аныдөрес куя белүгәирешү, рус сүзләре белән чагыштырып күрсәтү. Басымлы иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес уку һәм матур язу күнекмәләре булдыру.
2. Басымның үзенчәлекле очракларын белү.
3. Сингармонизм законының асылын гамәли үзләштерү.
4. Җөмлә ахырында нокта, сорау яки өндәү билгеләрен куеп, язу күнекмәләрен гомумиләштерү.
5. Орфоэпик һәм орфографик яктан сөйләмне оештыру эшен тирәнәйтү.

**Тынлап аңлауны бәяләү**

Тыңланган татар сөйләмен тулаем аңлап, төп эчтәлеген сөйләп бирә алганда, «5»ле куела.
Тыңланган татар сөйләмен аңлап, эчтәлеген якынча дөрес сөйли алганда, «4»ле куела.
Тыңланган татар сөйләмен аңлап, эчтәлеген өлешчә генә сөйли алганда, «3»ле куела.
Тыңланган татар сөйләменең эчтәлеген тулаем аңламаганда, «2»ле куела.

**Диалогик сөйләмне бәяләү**

Бирелгән ситуация яки лексик тема буенча әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес, эчтәлеге ягыннан эзлекле һәм тулы диалогик сөйләм төзегәндә, **«5»ле** куела.

Бирелгән ситуация яки лексик тема буенча репликаларның әйтелешендә һәм аерым сүзләрнең грамматик формаларында 2 — 3 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлекле диалогик сөйләм төзегәндә, «4»ле куела.

Өстәмә сораулар ярдәмендә генә әңгәмә кора алганда, репликаларның әйтелешендә һәм сүзләрнең грамматик формаларында 4 — 6 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлексез диалогик сөйләм төзегәндә, «3»ле куела.

Бирелгән ситуаиия яки лексик тема буенча диалог төзи алмаганда, «2»ле куела.

**Монологик сөйләмне бәяләү**

Әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес һәм эчтәлеге ягыннан тулы, эзлекле монологик сөйләм өчен «5»ле куела.

Аерым сүзләрнең әйтелешендә, грамматик формаларында яки җөмлә төзелешендә 2 — 3 хатасы булган, эчтәлеге ягыннан тулы монологик сөйләм өчен «4»ле куела.

Сүзләрнең әйтелешендә, җөмлә төзелешендә 4 — 6 хаталы, эчтәлеге ягыннан эзлекле булмаган монологик сөйләм өчен «3»ле куела.

Лексик темага монолог төзи алмаганда, «2»ле куела.

**Укуны бәяләү**

Текстның эчтәлеген тулаем аңлап, сәнгатьле итеп укыганда, «5»ле куела.

Текстның эчтәлеген аңлап, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп укыганда, әмма 2—3орфоэпик хата (авазларның әйтелешен бозу, басымны дөрес куймау, интонацияне сакламау) булганда, «4»ле куела.

Текстның эчтәлеген өлешчә аңлап укыганда, 4 — 6 тупас орфоэпик хата булганда, «3»ле куела.

Текстның эчтәлеген тулысынча аңламыйча, орфоэпик кагыйдәләрне бозып укыганда, «2»ле куела.

**Язма эшләрне тикшерү**

Башлангыч мәктәптә, укучыларның телдән сөйләм күнекмәләре белән бергә, язу һәм язма сөйләм күнекмәләре дә үсеш алырга тиеш. 1 нче сыйныфта балалар баш һәм юл хәрефләрен, кыска сүзләрне һәм җөмләләрне күчереп язарга күнегәләр. Укучыларның язу күнекмәләрен тикшергәндә, мондый күләмне истә тотарга кирәк: 1 нче сыйныфта 1 юл; 2 нче сыйныфта 2 юл; 3 нче һәм 4 нче сыйныфларда 4 юл.

2-4 нче сыйныфларда татар теленнән язма эшләр ике төркемгә бүленә:

1) өйрәтү эшләре (изложеяне, сочинение);

2) контроль эшләр (күчереп язу, сүзлек диктанты, диктант).

1—2 нче сыйныфларда аерым җөмләләрне яки бәйләнешле текстны үзгәрешсез күчереп язу таләп ителсә, 3—4 нче сыйныфларда сүзләрне кирәкле формада куеп яки нокталар урынына туры килгән сүзләрне куеп күчереп язу эшләре кулланыла.

Диктант яздыру өчен, төрле характердагы тел материалы (аерым сүзләр, аерым җөмләләр, бәйләнешле текст) сайланырга мөмкин. Диктант яздыру өчен сайланган бәйләнешле текст уртача авырлыкта, эчтәлеге һәм грамматик төзелеше ягыннан укучыларга аңлаешлы булырга тиеш, ә инде үзләштерелмәгән сүзләр очраса, укытучы аларны тактага язып аңлата.

Укучыларның язма сөйләм күнекмәләрен тикшергәндә, эчтәлекнең тулылыгына һәм эзлеклелегенә, җөмлә калыпларының грамматик яктан дөреслегенә һәм төрлелегенә игътибар итәргә кирәк. Язма эшләрнең эчтәлеген бәяләү белән беррәттән, укытучы орфографик һәм пунктуацион хаталарны да төзәтергә тиеш. Күп эшләрдә бер ук төрле хата кабатланса, бу кагыйдәне тагын бер тапкыр аңлату һәм дәрестә аңа махсус туктату сорала. Әгәр дә хаталар индивидуаль характерда булса, укучылар белән шәхси эш алып барырга кирәк.

1—2 нче сыйныфларда орфографик хаталарга гына игътибар ителсә, 3 — 4 нче сыйныфларда пунктуация хаталары да исәпкә алына. Хәрефне төшереп калдыру, кирәкмәгән хәреф өстәп яки хәрефләрнеалыштырып язу, сүзне юлдан-юлга дөрес күчермәү орфографик хатага карый. Әгәр дә сүз берничә урында дөрес, ә аерым бер урында хаталы язылган икән, бу ялгыш дип саналмый. Бер үк хата берничә сүздә кабатланса, бу бер ялгыш дип исәпләнә.

Тикшерү характерындагы язма эшләр, программаның иң әһәмиятле бүлекләрен үткәч, чирек яки уку елы ахырында уздырыла, һәм укучыларның билгеләре сыйныф журналына куела. Өйрәтү характерындагы язма эшләргә килгәндә, аларнын санын һәм төрләрен укытучы үзе билгели, һәм бу очракта сыйныф журналына бары тик ундй билгеләр генә куела.

**Контроль күчереп язуны бәяләү**

Пөхтә, төгәл һәм орфографик хатасыз язылган эшкә «5»ле куела.

Пөхтә, төгәл язылган, әмма 1—3 төзәтүе яки 1—2 орфографик хатасы булган эшкә «4»ле куела.

Пөхтә һом төгәл язылмаган, 4—5 төзәтүе яки 3—5 орфографик хатасы булган эшкә «3»ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 6 яки артыграк орфографик хатасы булган эшкә «2»ле куела.

**Диктантны бәяләү**

Пөхтә һәм төгәл язылган, 1 орфографик хаталы диктантка «5»ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылган, 2—3 орфографик хаталы диктантка «4»ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 4—6орфографик хаталы диктантка «3»ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 7 яки артыграк орфографик хаталы диктантка «2»ле куела.

**Язма сөйләмне бәяләү**

2—4 нче сыйныфларда укучыларның язма сөйләм күнекмәләрен үстерү өчен, өйрәтү характерындагы изложениеләр һәм сочинениеләр яздырыла. Аларны бәяләгәндә,

эшнең эчтәлеге ягыннан тулы һәм эзлекле язылуы, грамоталы булуы исәпкә алына. Башлангыч сыйныфларда изложение һәм сочинениеләр өчен бер билге куела.

Эзлекле язылган, 1 орфографик һәм 1 пунктуацион яки 1 грамматик хаталы эшкә «5»ле куела.

Эзлекле язылган, ләкин эчтәлектә ялгыш җибәрелгән, 2—3 орфографик һәм пунктуацион яки 2—3 грамматик хаталы эшкә «4»ле куела.

Эзлекле язылмаган, 4—6 орфографик һәм пунктуацион яки 4—6 грамматик хаталы эшкә «3»ле куела.

Эзлекле язылмаган һәм эчтәлеге ачылмаган, 7 дән артык орфографик һәм пунктуацион яки 7дән артык тупас грамматик хаталы эшкә «2»ле куела.

**Бәяләү нормалары**

**Язу:** (каллиграфик матур язу 2 юл).Орфографик хаталарга гына игътибар ителә; әгәр дә сүз берничә урында дөрес, ә аерым бер урында хаталы язылган икән ,бу ялгыш дип саналмый. Бер үк хата берничә сүздә кабатланса, бу бер ялгыш дип исәпләнә.

1) **контроль күчереп язу (1)-**3-4 җөмлә. Пөхтә, орфографик хатасыз язылган эшкә **“5”**ле; ...әмма 1-3 төзәтүе яки 1-2 орфографик хатасы булса **“4”**ле; пөхтә язылмаса, 4-6 орфографик хатасы булса “3” ле, пөхтә булмаса, 6,артыграк орфографик хатасы булса “2”ле куела.

**2) контроль сүзлек диктанты (4)** Пөхтә ,1орфографик хатасы булса **“5”**ле; пөхтә, 2-3 орфографик хатасы булса **“4”**ле; пөхтә язылмаган, 4-6 орфографик хатасы булса “3”ле; пөхтә түгел, 7, артыграк хатасы булса “2”ле куела.

**3) язма сөйләм** (изложение) күнекмәләрен үстерү өчен, өйрәтү характерында яздырыла, бер билге куела.Өйрәтү характерындагы язма эшләрнең уңай билгеләре генә журналга куела.

Бирелгән темага эзлекле язылган,1 орфографик һәм 1 грамматик хатасы булса **“5”**ле; эзлекле язылган,ләкин эчтәлектә ялгыш җибәрелгән, 2-3 орфографик яки 2-3 грамматик хатасы булса**”4”**ле; эзлекле язылмаган, 4-6 орфографик яки 4-6 грамматик хатасы булса “3” ле, эзлекле язылмаган һәм эчтәлеге ачылмаган, 7дән артык орфографик яки 7дән артык тупас грамматик хатасы булган эшкә “2”ле куела

**4)Диктант**

Пөхтә ,1орф-к хатасы булса **“5”**ле; пөхтә, 2-3 орф-к хатасы булса **“4”**ле; пөхтә язылмаган, 4-6 орф-к хатасы булса “3”ле; пөхтә түгел, 7, артыграк хатасы булса “2”ле куела.

**Йомгаклау билгесе** чирек һәм ел ахырында куела. Ул, укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен, татар телендә аралаша алу осталыгын, шулай ук язма эшләрнең нәтиҗәләрен исәпкә алып куелырга тиеш.

**Тест:**

“5” – 95-100%
“4” – 94 – 80%
“3” – 66 – 79%

- “2” – 65%тан кимрәк.

## 11. Укыту предметының эчтәлеге

УМК Федераль дәүләт стандартларының төп нигезләмәләренә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларын исәпкә алып төзелде.

1. Телне аралашу аша өйрәнү принцыбы нигезендә УМК өчен материал 4 нче сыйныф балаларының аралашу сфераларын исәпкә алып сайланды. 400-420 сүзгә 4 нче сыйныфта 125-130 чамасы яңа сүз кушыла. Продуктив лексика якынча 480-500 сүз

2. Телне ятлап түгел, ә актив фикерләп өйрәнү принцибы.

3. Укыту процессын шәхси индивидуальләштерү принцибы.

4. Телне функциональ төстә өйрәнү принцибы.

| № | Бүлекләр, темалар |
|---|---|
| 1 | Яңа укуелы котлы булсын! (Белем бәйрәме) |
| 2 | Туган як табигате |
| 4 | Кошлар һәм хайваннар дөньясында (Хайваннар дөньясында) |
| 5 | Кышкы уеннар |
| 6 | Минем дусларым |
| 7 | Дүрт аяклы дусларыбыз |
| 8 | Яз килә (Язгы бәйрәмнәр) |
| 9 | Татарстан (Минем туган илем) |
| 10 | Матур җәй җитә (Чәчәкле җәй, ямьле җәй) |
| | Контроль эшләр |
| | Хаталар өстендә эш |
| | **Барлыгы:136сәг.** |

**Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру**

| № | Дәрес темасы | Уку эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | 3 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау. Яңа уку елы котлы булсын! | Сүзлек белән эш, фонетик зарядка, җөмләләрне киңәйтеп язу. | 2.09 |
| 2. | Яңа уку елы котлы булсын! | Күнегүләр эшләү, җөмләләр төзү. | 3.09 |
| 3. | Уку – язу әсбаплары. Кереш контроль тест.№1. | Контроль эш эшләү. | 5.09 |
| 4. | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше | күнегүләр өстендә эшләү. | 6.09 |
| 5 | С.Маршак “Һәр атнада җиде көн” | сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү. | 9.09 |
| 6 | Сузык авазлар, тартык авазлар | Дөрес әйтеп транскрипция билгеләре белән язу | 10.09 |
| 7 | О, ы, э хәрефләре | Грамматик күнегүләр, транскрипция билгеләре белән язу | 12.09 |
| 8 | Р. Миңнуллин “Үсми калган хәреф” | Сәнгатьле уку, сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү. | 13.09 |
| 9. | 1-10 га кадәр һәм дистә саннар | Грамматик күнегүләр, җөмләләр төзү, сораулар кую. | 16.09 |
| 10. | “Эш урыны” хикәясе | Сәнгатьле уку, сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү. | 17.09 |
| 11 | Х.Гарданов “К хәрефе” шигыре | Сәнгатьле уку, сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү. | 19.09 |
| 12 | Текст “Алсу” | Сәнгатьле уку, сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү. | 20.09 |
| 13 | Текст “Алсу”. Иң яхшы сөйләүчегә конкурс. | Монологик сөйләм. | 23.09 |
| 14 | Сәгать ничә? | Сорауга-җавап, диалог төзү, дәреслек белән эш, сүзлек белән эш. | 24.09 |
| 15 | Г.Тукай “Эш беткәч уйнарга ярый” | Сәнгатьле уку, сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү. | 26.09 |
| 16 | Г.Тукай “Сабыйга” | Сәнгатьле уку, сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү. | 27.09 |
| 17. | Күнегүләр өстендә эш | күнегүләр эшләү. | 30.09 |
| 18. | Тест №1. Тема “Яңа уку елы котлы булсын” | Тест биремнәре эшләү | 1.10 |
| 19 | Хаталар өстендә | Хаталар өстендә эшләү | 3.10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | эш. Туган як табигате. | | |
| 20. | Үткән заман хикәя фигыль | Коммуникатив биремнәр эшләү. | 4.10 |
| 21 | Көз темасына әңгәмә | Фронталь әңгәмә, сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү. | 7.10 |
| 22. | Көзге табигать | Фронталь әңгәмә, сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү. | 8.10 |
| .23 | Кая? Кайда? Кайдан? сораулары | Җөмләләр төзү | 10.10 |
| 24 | Кемне? Нәрсәне? сораулары | Җөмләләрдә рәсемнәр урынына сүзләр куеп язу. | 11.10 |
| 25. | Кошлар безнең дусларыбыз Сүзлек диктанты. | Сүзлек диктанты | 14.10 |
| 26. | Канатлы дуслар | Фронталь әңгәмә, сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү. | 15.10 |
| 27. | Нәрсә? Нәрсәне? Нәрсәнең? сораулары | Җөмләләрдә рәсемнәр урынына сүзләр куеп язу | 17.10 |
| 28 | “ Песнәк белән Әнисә”хикәясе. Г.Лотфидан | Сәнгатьле уку, сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү. | 18.10 |
| 29. | Хәзерге һәм үткән заман хикәя фигыльнең юклык формасы | Грамматик күнегүләр, тәрҗемә итү. | 21.10 |
| 30 | Җ. Тәрҗеманов “Чирик”(1б.) | Сәнгатьле уку, сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 22.10 |
| 31. | Контроль эш №1. Тема: Туган як табигате | Контроль эш эшләү | 24.10 |
| 32 | Җ. Тәрҗеманов “Чирик”(2 б.) | Сәнгатьле уку, сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 25.10 |
| 33. | Инфинитив+ярата төзелмәсе | Ситуатив күнегүләр, тәрҗемә итү, сүзлек эше. | 28.10 |
| 34. | Бәйлекләр | Тәрҗемә итеп язу, күнегүләр өстендә эш, җөмләләр төзеп язу. | 29.10 |
| 35. | Хаталар өстендә эш.Исемнәрнең тартым белән төрләнеше | Хаталар өстендә эш эшләү | 7.11 |
| 36. | Күплек сандагы исемнәрнең тартым белән төрләнеше | Грамматик күнегүләр | 8.11 |
| 37. | Хаталар өстендә эш. Күнегүләр эшләү | күнегүләр эшләү | 11.11 |
| 38 . | Йорт һәм кыргый хайваннар | Фронталь әңгәмә, сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү. | 12.11 |
| 39 | Әнәс Кари “Тиен | сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү. | 14.11 |
| 40 | Билгесез үткән заман хикәя | Җөмләләр язу, тәрҗемә итү. | 15.11 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | фигыль | | |
| 41 | Г.Тукай “Ташбака белән Куян” | Сәнгатьле уку, сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 18.11 |
| 42 | Сыйфат дәрәҗәләре | Грамматик. күнегүләр, сүзлек эше, комплиментлар әйтү | 19.11 |
| 43 | Кая? Кайда? Кайдан? сораулары | Кая? Кайда? Кайдан? сорауларына җавап бирү | 21.11 |
| 44 | “Яшел энәле керпе” әкияте | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 22.11 |
| 45 | “Яшел энәле керпе” әкияте | Диалогик, монологик сөйләм. | 25.11 |
| 46 | Табышмаклар илендә | сорауларга җаваплар бирү, табышмаклар төзү | 26.11 |
| 49 | Кыш билгеләре | Фронталь әңгәмә, монологик сөйләм. | 28.11 |
| 50 | Сыйфатның артыклык дәрәҗәсе | Грамматик. күнегүләр, сүзлек эше, | 29.11 |
| 51 | Сорау алмашлыклары | Сораулар төзү. | 2.12 |
| 52 | Г.Бакир “Кышкы уен” | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 3.12 |
| 53 | Кышкы уеннар. Күчереп язу. | Күчереп язу. | 5.12 |
| 54 | Билгесез үткән заман хикәя фигыль | Җөмләләр язу, тәрҗемә итү. | 6.12 |
| 55 | Б.Рәхмәт “Яңа ел килгәч”шигыре | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 9.12 |
| 56 | Бәйлек сүзләр, кушма сүзләр | Җөмләләр төзү. | 10.12 |
| 57 | “Елга буенда” хикәясендәге лексик-грамматик материал | Яңа сүзләр өйрәнү, җөмләләр төзү. | 12.12 |
| 58 | Хикәя “Елга буенда” | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 13.12 |
| 59 | Хикәя “Елга буенда” | Диалогик, монологик сөйләм. | 16.12 |
| 60 | Контроль эш. | Контроль эш эшләү. | 17.12 |
| 61 | “Кышкы уеннар” | Диалогик сөйләм. | 19.12 |
| 62 | Шуа белә, шуа белми структурасы.Хаталар өстендә эш. | Җөмләләр төзү. | 20.12 |
| 63 | Җ . Дәрзаман “Камыраяк” | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 23.12 |
| 64 | “Кышкы уеннар” темасын кабатлау | Диалогик, монологик сөйләм. | 24.12 |
| 65 | “Кышкы уеннар” темасын кабатлап биремнәр эшләү | биремнәр эшләү | 9.01 |
| 66 | А.Алиш “Куян кызы | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 10.01 |
| 67 | Күнегүләр өстендә | Күнегүләр эшләү. | 13.01 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | эш | | |
| 68 | Йомгаклап кабатлау | Биремнәр үтәү. | 14.01 |
| 60 | Исемнәрнең зат-сан белән төрләнеше | Сүзлек эше, грамматик күнегүләр | 16.01 |
| 70 | “Минем дустым” темасына сөйләшү | Монологик сөйләм. | 17.01 |
| 71 | Чөнки теркәгече | Җөмләләр төзү. | 20.01 |
| 72 | Г. Бәширов “Сылтау” | | 21.01 |
| 73 | Сүз ясагыч кушымчалар:-чы/че | Грамматик күнегүләр, җөмләләр төзү | 23.01 |
| 74 | И. Туктар “Алма” | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 24.01 |
| 75 | Сочинение “Минем якын дустым” | Сочинение | 27.01 |
| 76 | Уйный башлады төзелмәсе | Таблица буенча эшләү. | 28.01 |
| 77 | Д.Аппакова “Шыгырдавыклы башмаклар”1 кисәк | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 30.01 |
| 78 | Д.Аппакова “Шыгырдавыклы башмаклар”2 кисәк | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 31.01 |
| 79 | Хәзерге заман, үткән заман хикәя фигыль | Күнегүләр өстендә эш. Җөмләләр төзү. | 3.02 |
| 80 | Д.Аппакова “Шыгырдавыклы башмаклар”3 кисәк | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 4.02 |
| 81 | Кая? Кайда? Кайдан? сораулары | Күнегүләр өстендә эш. Репликалар өстендә эшләү. | 6.02 |
| 82 | Кайдан? кая кадәр? | Рәсемнәр буенча эшләү. | 7.02 |
| 83 | Билгесезлек алмашлыклары | Күнегүләр эшләү. | 10.02 |
| 84 | “Дуслык” темасын кабатлау | Фронталь әңгәмә, монологик сөйләм | 11.02 |
| 85 | Тест №3. Тема: Минем дусларым. | Тест биремнәрен үтәү. | 13.02 |
| 86 | Минем дүрт аяклы дустым бар | Хикәя төзү. | 14.02 |
| 87 | Р.Мингалим “Дөньяда бер эт бар иде” | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 17.02 |
| 88 | Г.Тукай “Кызыклы шәкерт” | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 18.02 |
| 89 | Уйныйсы килә төзелмәсе | Грамматик күнегүләр, рәсемнәр буенча җөмләләр төзеп язу. | 20.02 |
| 90 | Исемнәрдә –сыз/сез аффикслары | парларда эш, дәреслек белән эш, сүзлек белән эш | 21.02 |
| 91 | Г. Мөхәммәтшин “Ак песи” хикәясе | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 24.02 |
| 92 | Г.Мөхәммәтшин | Диалогик, монологик сөйләм. | 25.02 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | “Ак песи” | | |
| 93 | Хәзерге, үткән заман хикәя фигыль | парларда эш, дәреслек белән эш, сүзлек белән эш | 27.02 |
| 94 | Кая? Кайда? Кайдан? сораулары | парларда эш, дәреслек белән эш, тактада эш, җөмләләр төзү | 28.02 |
| 95 | Р.Батулла “Чикыл белән Мырый” | | 3.03 |
| 96 | Р.Батулла “Чикыл белән Мырый” | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 4.03 |
| 97 | Йөгерә башлый төзелмәсе | Җөмләләр төзү. | 6.03 |
| 98 | “Дүртаяклы дусларыбыз” темасын кабатлау | Диалогик, монологик сөйләм | 7.03 |
| 99 | Күнегүләр өстендә эш | Күнегүләр эшләү. | 10.03 |
| 100 | Контроль эш№3. Тема: “Дүртаяклы дусларыбыз” | Контроль эш | 11.03 |
| 101 | Хаталар өстендә эш. Язгы бәйрәмнәр | Хаталар өстендә эш. | 13.03 |
| 102 | Яз килә | схема белән эш, дәреслек белән эш, җөмләләр төзү, сүзлек бәлән эш | 14.03 |
| 103 | Карга боткасы | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 17.03 |
| 104 | Л. Толстой “Әбисе белән оныгы” | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 18.03 |
| 105 | Парлы сүзләр | парларда эш, дәреслек белән эш, тактада эш, рәсемнәр ярдәмендә җөмләләр төзү | 31.03 |
| 106 | Ничек әдәпле сорарга? | парларда эш, дәреслек белән эш, сүзлек белән эш | 1.04 |
| 107 | М.Газизов “Рәхмәт” | парларда эш, дәреслек белән эш, сүзлек белән эш | 3.04 |
| 108 | Тест №4. Тема: “Яз килә” | тест | 4.04 |
| 109 | Хаталар өстендә эш. Гади саннар, кушма саннар | Хаталар өстендә эш. | 7.04 |
| 110 | Минем Ватаным - Татарстан | парларда эш, дәреслек белән эш, тактада эш, җөмләләр төзү | 8.04 |
| 111 | Татарстанның дәүләт символлары | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 10.04 |
| 112 | Татарстанның башкаласы - Казан | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 11.04 |
| 113 | Татарстан шәһәрләре. Сүзлек диктанты. | Сүзлек диктанты. | 14.04 |
| 114 | Туган җирем - Алексеевск | Диалогик, монологик сөйләм. | 15.04 |
| 115 | “Минем Ватаным” темасын кабатлау дәресе | Күнегүләр эшләү. | 17.04 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 116 | Инша “Татарстан – минем туган ягым” | Инша язу. | 18.04 |
| 117 | Хаталар өстендә эш. Күренекле шәхесләр | Хаталар өстендә эш | 21.04 |
| 118 | Җәйге табигать | Монологик сөйләм | 22.04 |
| 119 | Шәүкәт Галиев “Җәйге болында” | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 24.04 |
| 120 | Г.Нәбиуллин “Урман сөйләшә” | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 25.04 |
| 121 | Җәйге урман. | Диалогик сөйләм. | 28.04 |
| 122 | Җиләк - җимешләр | Рәсем буенча сөйләү. | 29.04 |
| 123 | Р. Корбан “Җиләктә” | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү,сорауларга җаваплар бирү, күнегүләр эшләү | 1.05 |
| 124 | Җәйге ял. | Монологик сөйләм | 2.05 |
| 125 | Җәй темасына ситуатив биремнәр | ситуатив биремнәр | 5.05 |
| 126 | Ел фасыллары. | Диалогик сөйләм | 6.05 |
| 127 | Ел фасыллары. | Монологик сөйләм | 8.05 |
| 128 | Еллык контроль эш | Контроль эш | 9.05 |
| 129 | Хаталар өстендә эш. | Хаталар өстендә эш | 12.05 |
| 130 | Күңелле җәй | Монологик сөйләм | 13.05 |
| 131 | Җәйге бакча. | Диалогик сөйләм | 15.05 |
| 132 | Җәйге бакча. | Монологик сөйләм | 16.05 |
| 133 | Йомгаклап кабатлау | Күңелле грамматик күнегүләр, ребуслар, кроссвордлар, орфографик-грамматик уеннар | 19.05 |
| 134-135 | Йомгаклап кабатлау | Күңелле грамматик күнегүләр, ребуслар, кроссвордлар, орфографик-грамматик уеннар | 20.05 |
| 136 | Гомумиләштереп кабатлау | Күңелле грамматик күнегүләр, ребуслар, кроссвордлар, орфографик-грамматик уеннар | 22.05 |

Пронумеровано, прошнуровано
и скреплено печатью
Всего: 13 (тринадцать) листов
Учитель: Хуснутдинова Г.С.

Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Алексеевская средняя общеобразовательная школа №2 с углубленным изучением отдельных предметов» ИНН 1605001185